# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# АКТАНЫШ МУНУЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# АКТАНЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

№ 25 13 сентябрь 2018 ел

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Актаныш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Актаныш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына 2018 елның 25 июнендәге 18 номерлы Совет карары проектының ачык тыңлаулар нәтиҗәләренә карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында", Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Актаныш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 85,86,87 матдәләренә нигезләнеп, Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Советы

карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Советының 2011 елның 24 июнендәге 7 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Актаныш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләр кертергә::

**1) 6 статьяның 1 бүлегендә:**

**а) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

"9) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;

**б) 14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

"14) каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу;»;

**2) 7 статьяның 1 бүлегендә:**

**а) 11 пункт үз көчен югалткан дип танырга;**

**б) 15-16 пунктны түбәндәге эчтәлек белән тулыландырырга:**

"15) инвалидлар, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар, адаптив физик культура һәм адаптив спорт үсешенә ярдәм күрсәтү;

16) «Кулланучылар хокукларын яклау турында" 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру.»;

**3) 11 статьяның 7 пункты** «гавами тыңлаулар»дан соң түбәндәге эчтәлектәге сүзләр өстәргә: «иҗтимагый фикер алышулар;»

**4) 19.1 статьяны түбәндәге эчтәлек белән тулыландырырга:**

"19.1.статья. Авыл торак пункты старостасы

1. Авыл җирлегендә урнашкан җирле мәсьәләләрне хәл иткәндә җирле үзидарә органнары һәм авыл халкы арасында үзара бәйләнешне оештыру өчен авыл торак пункты старостасы билгеләнергә мөмкин.

2. Авыл торак пункты старостасы составына әлеге авыл җирлеге территориясендә яшәүче һәм актив сайлау хокукына ия кешеләр арасыннан авыл торак пункты кергән Совет тарафыннан билгеләнә.

3. Авыл торак пункты старостасы дәүләт вазыйфасын, дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын, муниципаль вазыйфа яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын үтәүче зат түгел, хезмәт мөнәсәбәтләрендә һәм алар белән турыдан-туры бәйле башка мөнәсәбәтләрдә була алмый.

Россия Федерациясе субъекты законы белән, тарихи һәм башка җирле традицияләрне исәпкә алып, авыл торак пункты старостасы вазыйфасының башка исеме билгеләнергә мөмкин.

4. Авыл торак пункты старостасы итеп түбәндәге зат билгеләнә алмый:

1) дәүләт вазыйфасын, дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын, муниципаль вазыйфа яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын үтәүче;

2) суд тарафыннан эшкә яраксыз яисә юридик хокуклары чикле дип танылган;

3) Хөкем ителүе сүндерелмәгән яки юкка чыгарылмаган зат.

5. Авыл торак пункты старостасының вәкаләтләре авыл җирлеге Уставы белән билгеләнә һәм ул кимендә ике һәм биш елдан да ким була алмый.

Авыл торак пункты старостасының вәкаләтләре авыл җирлеге Советы карары буенча вакытыннан алда туктатыла, аның составына әлеге авыл торак пункты керә, шулай ук Уставның 39 статьясындагы 1 өлешенең 1 - 7 пунктлары белән билгеләнгән очракларда.

6. Авыл торак пункты старостасы үзенә йөкләнгән бурычларны хәл итү өчен:

1) авыл торак пунктында җирле мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр һәм башка оешмалар белән хезмәттәшлек итә;

2) халык белән гражданнар җыеннарында, җыелышларында, конференцияләрендә катнашу юлы белән хезмәттәшлек итә, мондый чаралар нәтиҗәсендә мөрәҗәгатьләрне һәм тәкъдимнәрне, шул исәптән җирле үзидарә органнары тарафыннан мәҗбүри карап тикшерелергә тиешле муниципаль хокукый актлар проектлары рәвешендә рәсмиләштерелгән тәкъдимнәрне җибәрә;

3) авыл халкына җирле үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләрен хәбәр итә, шулай ук җирле үзидарә органнарыннан алынган башка мәгълүматны җиткерүдә ярдәм итә;

4) җирле үзидарә органнарына халык тыңлаулары һәм җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрүдә, авыл торак пунктында аларның нәтиҗәләрен халыкка җиткерүдә ярдәм итә;

5) Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә җирлек уставында һәм (яки) җирлек Советының норматив хокукый актында каралган башка вәкаләтләрне һәм хокукларны гамәлгә ашыра.

7. Эш гарантияләре һәм авыл торак пункты старостасы статусының башка мәсьәләләре Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә җирлек уставы һәм (яки) җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә ала.»

**5) 20 статьяда:**

**а) статьяның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«20 статья. Җәмәгать тыңлаулары, фикер алышулар»;

**б) 3 пунктның 3 өлеше гамәлен югалткан дип санарга;**

**в) 3 өлешне түбәндәге эчтәлектәге 2.1 пункты белән тулыландырырга:**

"2.1) җирлекнең социаль-икътисадый үсеше стратегиясе проекты;»;

**г) 10 өлештә** «ачык тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе» сүзләрен әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән “Проектлар һәм мәсьәләләр буенча ачык тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе” сүзләренә алмаштырырга;

**д) 11 өлешне түбәндәге эчтәлек белән тулыландырырга:**

«11. Генераль план проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне межалау проектлары, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, күрсәтелгән расланган документларның берсенә, җир кишәрлеген яисә капиталь төзелеш объектын шартлы рөхсәт ителгән файдалануга рөхсәт бирү турында карар проектлары, рөхсәт ителгән төзелеш объектларының чик параметрларыннан кире кагуга рөхсәт бирү турында карар проектлары буенча, җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән башка төр файдалану мәсьәләләре буенча җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең расланган кагыйдәләре булмаганда иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар үткәрелә, аларны оештыру һәм үткәрү тәртибе шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезләмәләрен исәпкә алып җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.»;

**6) 25.1 статьяны түбәндәге эчтәлек белән тулыландырырга:**

«25.1 статья. Халык җыены

1. Гражданнар җыены җирле үзидарәне халык тарафыннан турыдан-туры гамәлгә ашыру һәм җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда халыкның катнашуы формасы булып тора.

2. Гражданнар җыены «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда каралган очракларда һәм «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге составына керүче торак пунктта гражданнар җыенын үткәрү тәртибе турында» гы Положение нигезендә җирлек Советы карары белән расланган очракларда үткәрелә.

3. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясында каралган гражданнар җыены үткәрелергә мөмкин булган очраклар:

1) составына күрсәтелгән торак пункт керә торган, авыл җирлеге (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча әлеге торак пункт территориясен башка җирлек (муниципаль район) территориясенә кертә торган торак пункт керә;

2) җирлек Советы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә күрсәтелгән җирлекнең чикләрен үзгәртү, чикләрен үзгәртү мәсьәләләре буенча;

3) авыл җирлегендә сайлау хокукына ия халык саны 100 дән артык кеше булса, җирлек советын төзү, аның саны һәм вәкаләтләре вакыты турындагы мәсьәләне җирлек Советы вәкаләтләре гражданнар җыены белән гамәлгә ашырыла;

4) җирлек Советы вәкаләтләре гражданнар җыены белән гамәлгә ашырыла торган җирлектә, гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

5) авыл җирлеге составына керүче, шәһәр эче районы составына керүче торак пунктта, федераль әһәмияткә ия шәһәр округы территориясендә яки муниципаль район чикләрендә урнашкан шәһәр округы территориясендә, гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

6) халык арасында урнашкан торак пунктта җирле үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру белән бәйле мәсьәләләр буенча халык инициативасын тәкъдим итү максатларында;

7) авыл халкының тыгызлыгы түбән булган яисә авыр җирлекле территориядә яшәгән, халык саны 100 кешедән артмаган авыл җирлегендә җирлекне бетерү мәсьәләсе буенча;

8) авыл торак пунктында староста кандидатурасын тәкъдим итү мәсьәләсе буенча, шулай ук авыл торак пункты старостасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату мәсьәләсе буенча;

9) Россия Федерациясе законнарында муниципаль хезмәт турында каралган муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәргәндә, конкурс комиссиясе составына кандидатуралар тәкъдим итү максатларында авыл торак пунктында гражданнар җыены үткәрелә ала.

4. Гражданнар җыены Җирлек Башлыгы, я сайлау хокукы булган, исәбе 10 да ким булмаган җирлехалык төркеме инициативасы чакырылырга мөмкин.

5. Җыен уздыру инициативасын яклау өчен тиешенчә җыелган имзалар саны сайлау хокукы булган, даими яки өлешчә яшәүче, шушы җирлектә регистрацияләнгән гражданнарның 5 % исәбеннән булырга тиеш, ләкин имзалар саны 25 тән дә ким булырга тиеш түгел.

6. Җирлек Башлыгы тарафыннан чакырылган гражданнар җыены, муниципаль берәмлек башлыгы карары нигезендә билегләнә, инициативалы төркем тарафыннан чакырылган гражданнар җыены Җирлек Советы карары нигезендә билгеләнә.

7. Җирлек халкы гражданнар җыенының вакыты һәм урыны турында алдан ук хәбәр итәләр, алдан ук муниципаль хокук акты һәм гражданнар җыенында күтәреләсе сорауларның материаллары белән " Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлегенә керүче җирлектә җыен үткәрүне оештыру" нигезләмәсе белән танышалар.

8. Җыен вакытында кабул ителгән карарлар муниципаль хокук акты булалар, Җирлек Башлыгы тарафыннан имзаланалар һәм Татарстан Республикасы муниципаль норматив актлар регистрына кертелергә тиеш.

**7) 30 нчы матдәне 4-7 өлешләр белән баетырга:**

"4. Сайлаучыларның депутатлар белән очрашулары махсус бүлмәләрдә оештырылырга тиеш, һәм шулай ук ишегалды территориләрендә, әгәр дә җыен үткәрү транспорт һәм социаль инфраструктурага, элемтәгә, җәяүлеләрнең йөрешенә һәм (яисә) транспорт чараларының я гражданнарның йортларына, я транспорт һәм социаль инфрастуктура объектларына керү мөмкинлеген чикләмәсә. Мондый очрашулар турында Татарстан Республикасы башкарма хөкүмәтен яисә җирле үзидарә органнарын алдан хәбәр итү таләп ителми. Ләкин депутат югарыда әйтелгән органнарны алдан вакытын һәм урынын хәбәр итеп куерга хокуклы.

5. Җирлек советы депутатларның сайлаучылар белән очрашу урынын билгели, һәм шулай ук җирле үзидарә тарафыннан очрашу өчен бирелгән бүлмәләр исемлеген, һәм шушы бүлмәләр бирү тәртибен билгели.

6. Депутаталар белән очрашу публик чара формасында Россия Федерациясынең җыеннар, митинглар, демонстрацияләр, йөрешләр, пикетлар турындагы законы нигезендә үткәрелә.

7. Депутатларның публик формадагы сайлаучылар белән очрашуын оештыру яисә үткәрүенә комачау итү Россия Федерациясынең җыеннар, митинглар, демонстрацияләр, йөрешләр, пикетлар турындагы законы нигезендә Россия Федерациясынең кануннары нигезендә административ җаваплылыкка тартыла."

**8) 32 нче статьяда:**

а) 5 нче пунктны алдагы редакцияләрдә аңлатып бирергә:

"5) Җирлекнең социаль-икътисади үсеш стратегиясен расларга"

б) 36 нчы пункт белән алдагы эчтәлекне тулыландырырга.

"36) Җирлек территориясен яхшырту тәртибенең карарын кабул итү.

**9) 45 нче статьяны 5-6 нчы өлешләр кертеп алдагы эчтәлек белән тулыландырырга:**

"5. Әгәр дә Җирлек Башлыгы вакытыннан алда үзенең вазифаларын башкаруны туктатса, я мәхкәмә карары буенча сакка алынса, я вакытлыча вазифаларын башкарудан азат ителсә, аның вазифаларын дәүләт хезмәтендәге җирлеүзидарә кешесе я Җирлек Соыеты детпутаты Җирлек Уставы нигезендә башкара.

6. Әгәрдә Җирлек Башлыгы үзенең вазифаларын үтәүне, Татарстан Республикасы Президентының (Татартан Республикасы Премьер-министры) Җирлек Башлыгы вазифаларыннан баш тарту хокукый карары яисә Җирлек Советының Җирлек Башлыгын вазифаларыннан азат итү нигезендә эшләнсә, бу

хокукый актларны яисә карарларны мәхкәмә аша хәл итә ала, Җирлек Советы Җирлек Башлыгын Җирлек Советы сайлап кую турында конкурс комиссиясе тарафыннан конкурс нәтиҗәләре нигезендә мәхкәмә карары үзенең канунлы көчнә кергәнче карар кабул итә алмый."

**10) 48 нче статьяда:**

**а) 1 нче өлешнең 1 нче пунктын алдагы эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:**

"- 2014 нче елның 24 июненнән "Рәсәй Федерациясендә стратегик планлаштыру" 172-ФЗ буенча стратегик планлаштыру вәкәләтләре"

**б) 1 нче өлешне 10 нчы пункт белән алдагы эчтәлек белән тулыландырырга:**

"10) терроризмга каршы тору өлкәсендә, терроризмга карата профилактик эшләр буенча җирле сорауларны хәл итүдә катнашу, һәм шулай ук нәтиҗәдә килеп чыккан хәлләрне минимизацияләү һәм (яки) ликвидацияләү:

- Килеп чыккан хәлләрне минимизацияләү һәм (яки) ликвидацияләү сферасында терроризмга каршы муниципаль программаларны эшли һәм тормышка ашыралар.
- Терроризм турында һәм аның җәмгыятькә куркынычы турында муниципаль берәмлекләрдә терроризм турында аңлату буенча информацион-пропагада чаралары, һәм шулай ук гражданнарда терроризм идеологиясенә каршы булган фикер тудыру, шулай ук информацион материаллар, басма продукция, аңлату эшләре һәм башкалар оештыра.
- Терроризм профилактикасы буенча, һәм шулай ук килеп чыккан хәлләрне минимизацияләү һәм ликвидацияләү буенча Федераль башкарма хөкүмәт органнары һәм (яки) башкарма хөкүмәт оештырган чараларда катнашырга тиеш.
- Муниципаль милеккә караган я җирле үзидарәгә караган объектларның антитеррористик куркынычсызлыгын тәэмин итәргә тиеш.
- Терроризмны профилакцияләү буенча һәм килеп чыккан хәлләрне минимизацияләү һәм (яки) ликвидацияләү буенча тәкъдимнәрен Рәсәй Федерациясенең башкарма хөкүмәтенә җибәрә.
- Терроризмны профилакцияләгән килеп чыккан җирле сорауларны чишү һәм килеп чыккан хәлләрне минимизацияләү һәм (яки) ликвидацияләү.

**в) 2 нче өлешне алдагы эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:**

"- инвалидлар, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар, адаптив физик культура һәм адаптив спорт үсешенә ярдәм күрсәтү;

- «Кулланучылар хокукларын яклау турында" 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру.»;

**11) 66.1 статьяны түбәндәге эчтәлек белән тулыландырырга:**

"66.1 статья. Җирлекне төзекләндерү тәртибе эчтәлеге"

1. Җирлек территориясен төзекләндерү тәртибе Җирлек Советы карары нигезендә кабул ителә.

2. Җирлекне төзекләндерү тәртибе түбәндәге сорауларны карый ала:

1) Гомуми кулананыштагы территорияләрне һәм бу территорияләр белән кулланнуны.

2) Әйләнә-тирәдәге биналарның, корылмаларның, төзелешләрнең фасадларының тышкы кыяфәтен.

3) Төзелеш эшләренең элементларын проектлау, урнаштыру, күләмен, элементларын яңарту һәм шулай ук җир эшләре оештыруда да.

4) Җирлек территориясен, биналарны, төзелешләрне, корылмаларны, архитектур элементларны яктырту.

5) Җирлекне яшелләндерүне оештыруны, саклауны шулай ук газон, чәчәклекләр, ясауны, төзеклеген тәэмин итүне, кире торгызуны һәм башка үләнле территорияләрне.

6) Җирлек территориясендә күрсәтмә такталарны, урам атамаларын, йорт номерлары һәм эленмә такталарны урнаштыру.

7) Балалар, спорт мәйданчыкларын, хайваннарны көтү урыннарын, машина кую урыннарын,кече архитектур формаларны урнаштыру.

8) Җәяүлеләр коммуникацияләрен, шулай ук тротуарларны, аллеяларны, юлчыкларларны, сукмакларларны оештыру.

9) Җирлектә чиксез рәвештә хәрәкәт итү өчен мөмкинлеләре чикле булган һәм аз мобильлекле гражданнарга күрсәтелгән территория буенча территорияне оештырырга.

10) Җирлек территориясен җыештыру, шулай ук кышкы айларда да.

11) Язгы суларны агызып җибәрүне оештырырга.

12) Җир эшләрен оештыруны тәртип буенча оештырырга.

13) Бина, төзелеш, корылма хуҗаларының шушы территориягә караган җирлекне төзәекләндерүдә катнашу, шул ук вакытта финанс ягыннан да(искәрмә буларак шәхси милек хуҗалары я (яисә)башка төр күпфатирлы канунлы бүлмә хуҗалары, йорт тирәсендәге я йорт тирәсендә булмаган җир өлешләре чигендәге йортлар).

14) Рәсәй Федерациясе кануннары нигезендә янәшә булган территорияләрнең чикләрен билгеләү.

15) Җирлекне бәйрәмчә әзерләү.

16) Җирлекне төзекләндерүне оештырганда җирлек халкын катнаштыруны оештыру һәм реализациләү.

17) Территориянең төзекләндерүен оештыруны контрольгә алу.

3. Рәсәй Федерациясе кануны нигезендә башка төр сорауларда күз алланырга мөмкин, табигый, климатик, географик, социаль-икътисади һәм муниципаль берәмлекләргә карап башка төр үзенчәлекләрдә каралырга мөмкин.”

**12) 80 нче статьяны алдагы редакциядә аңлатып бирергә:**

“80 нче статья. Гражданнарны үзара салымлау”

1. Үзара салымлау дип гражданнарның бер тапкыр конкрет мәсьәләләрне чишү өчен түләнелгән матди чаралар күзаллана. Гражданнарның үзара салым күләме барлык яшәүчеләргә дә (Шәһәр әйләнәсенәкергән авыл составында булган җирлек) тигез абсолют зурлыкта билгеләнә, моннан кала искәрмә буларак аеры төр гражданнар өчен үзара салым күләме түбәнәйтелергә мөмкин, әгәрдә аларның саны гомуми халкының (Шәһәр әйләнәсенәкергән авыл составында булган җирлек) санынннан 30 процентын гына тәшкил итсә.

2. Гражданнарның бер тапкыр түләнә торган түләүләре турындагы хәзерге матдәнең 1 нче өлештә күрсәтелгәнсораулары җирле референдумда хәл ителә, ә “Рәсәй Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары” дигән федераль канунның 25.1 нче матдәсенең 4, 4.1., пунктларында күрсәтелгән очракларда халык җыенында.

**13) 3 өлешнең 85нче матдәнең икенче дәвамын алдагы редакциядәаңлатып бирергә:**

“Җирлек уставына үзгәрешләр кертү буенча муниципаль хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәр исәбен алу тәртибен халыкка игълан итү таләп ителми һәм шулай ук гражданнарның җәмагать әңгәмәсенә куелуы да, әгәр дә Җирлек Уставына төгәл формалы Рәсәй Федерациясе Конституциясе, федераль кануннар, Татарстан Конституциясе яисә Татарстан Республикасы кануннары нигезләмәләренә туры китереп бетерү максатыннан оештырыла ”

**14) 86 нчы матдәдә 13 нче өлешне алдагы тәкъдим белән тулыландырып бетерергә:**

“Әгәр дә Җирлек Башлыгы Җирлек Советы председателе вазифаларында үти икән, Җирлек Башлыгы тавышы Җирлек Уставын кабул иткәндә, Җирлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр керткәндә Җирлек Советы депутаты тавышы буларак исәпкә алына.”

**15) 87 нче маддәдә:**

**а) 3 нче бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«3. Җирлек җирле үзидарә органнары структурасын, җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләр бүлешү (Җирлек Уставын федераль кануннарга туры китерү, шулай ук вәкаләтләрне, вәкаләтләр вакытын һәм җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын сайлау тәртибен үзгәртү очракларыннан кала) үзгәртүче әлеге Уставка керткән үзгәрешләр, Җирлек Уставына әлеге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертү турында муниципаль хокукый акт кабул иткән Җирлек Советы вәкаләтләре вакыты чыкканнан соң үз көченә керә.»;

**б) түбәндәге эчтәлекле 5-7 бүлекләр белән тулыландырырга:**

«5. Җирлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр рәсмиләштерергә мөмкин булган муниципаль хокукый акт тарафыннан кертелә:

1) Җирлек башлыгы һәм рәисе кул куйган җирлек Советы (гражданнар җыены) карары яки җирлек башлыгы, җирлек Советы рәисе вәкаләтләрен башкаручы (гражданнар җыены);

2) Җирлек Советы (гражданнар җыены) тарафыннан кабул ителгән һәм җирлек башлыгы кул куйган аерым норматив хокукый акт белән. Бу очракта әлеге хокукый актта аны кабул итү турындагы җирлек Советы (гражданнар җыены) карарының реквизитлары куела. Җирлек Советының (гражданнар җыены) мондый карарына күчеш нигезләмәләрен һәм (яки) җирлек уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр үз көченә керү турындагы нормаларны кертү рөхсәт ителми.

6. Авыл җирлеге уставын Федераль законга, Татарстан Республикасы законына туры китерү әлеге закон актларында билгеләнгән срокта гамәлгә ашырыла. Әгәр федераль закон, Татарстан Республикасы законы белән күрсәтелгән срок билгеләнмәгән булса, җирлек уставын Федераль законга туры

китерү вакыты Татарстан Республикасы законы белән тиешле федераль закон, Татарстан Республикасы Законы үз көченә керү датасын, җирлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, г ражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу турындагы муниципаль хокукый акт проектының ачык тыңлауларында фикер алышуны, җирлек Советы утырышларының вакытлылыгы исәпкә алып билгеләнә, мондый муниципаль хокукый актны дәүләт теркәвенә алу һәм рәсми бастырып чыгару (халыкка игълан итү) сроклары, кагыйдә буларак, алты айдан да артмаска тиеш.

7. Җирлек Уставын яңа редакциядә бәян итү җирлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы муниципаль хокукый акт белән рөхсәт ителми. Бу очракта җирлекнең яңа Уставы кабул ителә, ә элек җирлекнең гамәлдәге Уставы һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы муниципаль хокукый актлар җирлекнең яңа Уставы үз көченә кергән көннән үз көчен югалткан дип таныла.».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге карар, үз көченә керүнең бүтән сроклары билгеләнгән нигезләмәләреннән кала, рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.

4. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Уставына өстәмәләр һәм үзгәрешләрне Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында дәүләт теркәве үткәннән соң урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет рәисе, Актаныш
авыл җирлеге башлыгы

Э.Н. Фәттахов